**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Бигеш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№131** **28.03.2024 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының 2022 елның 26 октябрендәге 79 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының « Бигеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының 2022 елның 26 октябрендәге 79 номерлы карары белән расланган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәреш кертергә:

«

Төзекләндерү өлкәсендә
муниципаль контроль
турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

## ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ӨЛКӘСЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ КЫСАЛАРЫНДА ТИКШЕРЕЛӘ ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘРНЕ БОЗУ КУРКЫНЫЧЫ ИНДИКАТОРЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

1. Җирлек территориясендә төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында муниципаль контроль органы күрсәтмәсен үтәү турында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң мәгълүмат булмау.

2. Муниципаль контроль органына җир эшләрен башкаруга рөхсәт срогы тәмамланганнан соң җир эшләре тәмамлану турында мәгълүматлар булмау турында мәгълүмат килү.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим..

**Совет Рәисе** **И.Р.Вәлиев.**